

Рузаевкада Боек флот житәкчесе Федор Ушаков бюсты урнаштырылды һәм Саранскта Социалистик хезмәт Герое, Мордва АССРнын атказанган табибы Анна Парамоноваrа багышланган мемориаль такта ачылды.

“Адмирал Ушаков Ватанга фидакарь хезмәт итv vрнәге.   Гомеренен сонгы елларын ул Темников жирендә vткәрә. Без аны Мордовиянен яклаучысы буларак хормәт итәбез. Анын турында истәлек безнен сугышчыларда, тормышын Хәрби-Дингез флоты белән бәйләгән һәркемдә яши”, - дип билгеләп vтте Мордовия башлыгы Артём Здунов.

Социалистик хезмәт Герое, Мордва АССРнын атказанган табибы Анна Парамонова житәкчелегендә Ичалкида хастаханә зур, kvп профильле дәвалау учреждениесенә әверелә: районда хастаханәнен ике дәвалау корпусы, поликлиника, ашыгыч ярдәм бvлеге, берничә ФАП, медицина хезмәткәрләре очен торак йортлар тозелә. Аннары ул Саранскта медицина vсешенә зур олеш кертә.